КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 июнь г.Казань № 487

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 октябрь, 713 нче; 2014 ел, 26 март, 187 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 18 июнь, 412 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 851 нче; 2017 ел, 23 июнь, 417 нче; 2018 ел, 14 июнь, 472 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

«Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | «Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
|---|---|
| 1. | Юридик затларны, физик затларны шәхси эшмәкәрләр һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары буларак дәүләт теркәвенә алу |
| 2. | Кызыксынган затларга дисквалификацияләнгән затлар реестрындагы мәгълүматларны бирү |
| 3. | Салым түләүчеләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү (күрсәтелгән реестрдан физик һәм юридик затлар соравы буенча күрсәтелгән реестрдан өземтәләр бирү өлешендә, салым серен үз эченә алган мәгълүматлардан тыш) |
| 4. | Салым түләүчеләрнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны бирү (салым серен үз эченә алган мәгълүматлардан тыш, физик затлар һәм юридик затлар сораулары буенча әлеге реестрдан чыгармалар бирү өлешендә) |
| 5. | Салым түләүчеләргә, җыемнар түләүчеләргә, иминият кертемнәре түләүчеләргә һәм салым агентларына гамәлдәге салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актлар, салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәрен исәпләү һәм түләү тәртибе, салым түләүчеләр, җыемнар түләүчеләр, иминият кертемнәре түләүчеләр һәм салым агентларының хокуклары һәм бурычлары турында, салым органнары һәм аларның вазыйфаи затлары вәкаләтләре турында (салым түләүченең (җыемнар түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәү турында белешмә соратып алу һәм бирү өлешендә) түләүсез мәгълүмат бирү (шул исәптән язма рәвештә) |
| 6. | Салым белдерүендә күрсәтелгән белешмәләрне төгәлләштерү турында салым белдерүенә гариза кабул итү |
| 7. | Салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисаплар торышы турында белешмә бирү хакында соратулар кабул итү |
| 8. | Салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисапларны бергәләп чагыштыру актын бирү турында соратулар кабул итү |
| 9. | Физик затлар өчен салым түләүченең шәхси кабинетына керү турында гариза кабул итү |
| 10. | Физик затның (аның законлы вәкиле яки вәкаләтле вәкиле) аның салым белдерү кәгазен алу турында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша шәхсән расписка астында гариза кабул итүе |
| 11. | Физик затның транспорт салымы, җир салымы, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым ташламалары бирү турында гаризасын кабул итү |
| 12. | Җир салымы буенча салым исәпләре кулланыла торган сайлап алынган җир участогы турында хәбәрнамә кабул итү |

| | |
|---|---|
| 13. | Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә кабул итү |
| 14. | Физик затлар түләгән тиешле салымнар буенча салым салу объектлары дип танылган күчемсез милек объектлары һәм (яки) транспорт чаралары турында хәбәрнамәләр кабул итү |
| 15. | Физик затлар керемենә салым буенча салым декларацияләренең салым органнарына салым түләүче физик затлар өчен кәгазьдә 3-НДФЛ формасы буенча салым декларацияләрен җибәрү |
| 16. | Физик затның салым органында исәпкә кую турында гаризасын кабул итү һәм физик затка исәпкә кую турында таныклык бирү (кабат бирү)»; |

«Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» бүлекчәсенә 12 нче пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| «12. | Пенсия алды яшендәге гражданнар категориясенә кертү турында гражданнарга мәгълүмат бирү»; |

«Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасындагы территориаль идарәсе» бүлекчәсе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт милке белән идарә итү буенча федераль агентлыкның Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендә төбәкара территориаль идарәсе»;

II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы», «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы» бүлекчәләрен өстәргә:

| «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | |
|---|---|
| 1. | Капиталь төзелеш объектын төзү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә планлаштырылган очракта һәм ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектын төзекләндергән очракта төзелешкә рөхсәт бирү, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук шәхси автомобиль юлларын төзүдән тыш, әгәр төзелеш, төзекләндерү эшләре ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә алып бару планлаштырылган очракта |
| 2. | Капиталь төзелеш объектын төзү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә гамәлгә ашырылган очракта һәм ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектын төзекләндергән очракта объектны файдалануга кертергә бирү, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге |

| | |
|---|---|
| | автомобиль юллары, шулай ук шәхси автомобиль юлларыннан тыш, әгәр төзелеш, төзекләндерү эшләре ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә алып барылган очракта |
| 3. | Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округлары, муниципаль районнар) территорияләрендә су объектында ясалма җир кишәрлеге төзү буенча эшләр башкаруга рөхсәт бирү |
| 4. | Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары, муниципаль районнар) территорияләрендә ясалма рәвештә төзелгән җир кишәрлеген файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү |
| Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | |
| 1. | Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары, шулай ук шәхси автомобиль юллары (алга таба – автомобиль юллары) төзелешенә рөхсәт бирү, автомобиль юлларын төзү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә планлаштырылган очракта һәм ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан автомобиль юлларын реконструкцияләгәндә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 5 өлешендә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш |
| 2. | Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук шәхси автомобиль юлларын (алга таба – автомобиль юллары) файдалануга кертергә рөхсәт бирү, автомобиль юлларын төзү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә планлаштырылган очракта һәм ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан автомобиль юлларын реконструкцияләгәндә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 5 өлешендә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш»; |

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «IV. Күпфункциональ үзәкләр яки алар тарафыннан җәлеп ителүче чит оешмалар күрсәтә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр | |
|---|---|
| 1. | Торак урынның техник паспортын, катлар планын бирү |
| 2. | Торак (торак булмаган) урынны яңадан үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планировкалау проектын әзерләү һәм рәсмиләштерү |

| | |
|---|---|
| 3. | 2000 елның 1 гыйнварына кадәр теркәлгән хокуклар турында реестрдан чыгарма бирү |
| 4. | Техник, межа планын, тикшерү актын әзерләү һәм рәсмиләштерү |
| 5. | Күчемсез милек объектларының базар бәясе |
| 6. | Банкомат хезмәтләре күрсәтү |
| 7. | Нотариаль хезмәтләр күрсәтү (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым күпфункцияле үзәкләрендә) |
| 8. | Күчермә алу, күбәйтү хезмәтләре күрсәтү |
| 9. | Гомуми файдаланудагы элемтәнең җирле, зона эчендәге челтәре хезмәтләрен күрсәтү |
| 10. | Белешмә хокук системаларыннан файдалану хезмәтләре күрсәтү |
| 11. | Граждан-хокук шартнамәләре проектларын әзерләү |
| 12. | Салым декларацияләрен тутыру |
| 13. | Дәүләт хезмәтләреннән үз-үзеңә хезмәт күрсәтү режимында электрон рәвештә файдалану өчен терминалдан (инфоматтан) файдалану хезмәтләре күрсәтү |
| 14. | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдалану хезмәтләре күрсәтү |
| 15. | Юридик консультация күрсәтү (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым күпфункцияле үзәкләрендә) |
| 16. | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бирү өчен гариза һәм документлар кабул итү өчен мөрәҗәгать итүчегә аның соарвы буенча бару, шул исәптән түләүсез (гражданнарның аерым категорияләре өчен) (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым күпфункцияле үзәкләрендә) |
| 17. | Физик затлар өчен электрон цифрлы имза эшләүгә гаризалар кабул итү |
| 18. | Күпфункцияле үзәк базасында дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен алу өчен кирәкле башка хезмәт күрсәтүләр |
| 19. | Мәгълүматны криптографик яклау чарасы белән җиһазландырылган цифрлы тахограф өчен машина йөртүче картасын эшләүгә гаризалар кабул итү |
| 20. | Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү өчен гаризалар кабул итү |

| | |
|---|---|
| 21. | Архив белешмәләрен, архив күчермәләрен, архив өземтәләрен, гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен үтәү белән бәйле мәгълүмат хатларын бирү |
| 22. | Банкта исәп-хисап счеты ачу өчен юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар гаризаларын кабул итү |
| 23. | «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимы буенча консультацияләр бирү |
| 24. | Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урнашу урыны буенча сайлаучылар, референдумда катнашучылар исемлегенә кертү тәртибе нигезендә федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар, Татарстан Республикасы референдумы уздырганда урнашу урыны буенча сайлаучылар, референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турында гаризалар кабул итү |
| 25. | Бөек Ватан сугышы ветераннары реестрына кертү һәм «Үлемсез полк» акциясендә катнашу өчен Бөек Ватан сугышы ветераннарының фотосурәтләрен түләүсез бастыру |
| 26. | Кертем кертүчеләрнең һәм акционерларның хокукларын яклау буенча федераль иҗтимагый-дәүләт фондында компенсация түләве алу өчен гражданнарны теркәү»; |

V бүлектә:

бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | |
|---|---|
| 1. | Юридик затларны, физик затларны шәхси эшмәкәрләр һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары буларак дәүләт теркәвенә алу |
| 2. | Мәнфәгатьле затларга дисквалификацияләнгән затлар реестрындагы мәгълүматларны бирү |
| 3. | Салым түләүчеләрнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны бирү (салым серен үз эченә алган мәгълүматлардан тыш, физик затлар һәм юридик затлар сораулары буенча әлеге реестрдан чыгармалар бирү өлешендә) |
| 4. | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы һәм Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны бирү (физик затлар һәм юридик затлар сораулары буенча әлеге реестрлардан чыгармалар бирү өлешендә, файдаланылу мөмкинлекләре чикләнгән мәгълүматларны үз эченә алган чыгармалардан тыш) |

| | |
|---|---|
| 5. | Салым түләүчеләргә, җыемнар түләүчеләргә, иминият кертемнәре түләүчеләргә һәм салым агентларына гамәлдәге салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актлар, салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәрен исәпләү һәм түләү тәртибе, салым түләүчеләр, җыемнар түләүчеләр, иминият кертемнәре түләүчеләр һәм салым агентларының хокуклары һәм бурычлары турында, салым органнары һәм аларның вазыйфаи затлары вәкаләтләре турында (салым түләүченең (җыемнар түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәү турында белешмә соратып алу һәм бирү өлешендә) түләүсез мәгълүмат бирү (шул исәптән язма рәвештә) |
| 6. | Салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисаплар торышы турында белешмә бирү хакында соратулар кабул итү |
| 7. | Салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисапларны бергәләп чагыштыру актын бирү турында сорату кабул итү»; |

түбәндәге эчтәлекле «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы», «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы» бүлекчәләрен өстәргә:

| «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | |
|---|---|
| 1. | Капиталь төзелеш объектын төзү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә планлаштырылган очракта һәм ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектын төзекләндергән очракта төзелешкә рөхсәт бирү, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук шәхси автомобиль юлларын төзүдән тыш, әгәр төзелеш, төзекләндерү эшләре ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә алып бару планлаштырылган очракта |
| 2. | Капиталь төзелеш объектын төзү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә гамәлгә ашырылган очракта һәм ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектын төзекләндергән очракта объектны файдалануга кертергә бирү, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары, шулай ук шәхси автомобиль юлларыннан тыш, әгәр төзелеш, төзекләндерү эшләре ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә алып барылган очракта |

| | |
|---|---|
| | |
| 3. | Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округлары, муниципаль районнар) территорияләрендә су объектында ясалма җир кишәрлеге төзү буенча эшләр башкаруга рөхсәт бирү |
| 4. | Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары, муниципаль районнар) территорияләрендә ясалма рәвештә төзелгән җир кишәрлеген файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү |
| Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | |
| 1. | Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары, шулай ук шәхси автомобиль юллары (алга таба – автомобиль юллары) төзелешенә рөхсәт бирү, автомобиль юлларын төзү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә планлаштырылган очракта һәм ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан автомобиль юлларын реконструкцияләгәндә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 5 өлешендә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш |
| 2. | Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук шәхси автомобиль юлларын (алга таба – автомобиль юллары) файдалануга кертергә рөхсәт бирү, автомобиль юлларын төзү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә планлаштырылган очракта һәм ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнашкан автомобиль юлларын реконструкцияләгәндә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 5 өлешендә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш»; |

«Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе | |
|---|---|
| 1. | Кредит һәм башка финанс ресурслары алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү |
| 2. | Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган программалар һәм ярдәмче программалар буенча дәүләт финанс ярдәме чаралары турында консультация бирү |
| 3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген хокукый тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация бирү |

| | |
|---|---|
| 4. | Эшмәкәрлекне популярлаштыруга һәм үз эшен башлап җибәрүгә юнәлдерелгән белем бирү чараларында катнашу мәсьәләләре буенча консультация бирү |
| 5. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү чаралары турында консультация бирү |
| 6. | Тышкы икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында консультация бирү |
| 7. | Кредит килешүе, займ килешүе, финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе яки банк гарантиясе килешүе буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты йөкләмәләрен тәэмин итү өчен җаваплылыкны үз өстенә алу буенча консультация бирү |
| 8. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен кредит оешмалары хезмәтләре турында консультация бирү |
| 9. | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә шикаять җибәрү мәсьәләсе буенча консультация бирү |
| 10. | Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан контроль-күзәтчелек чараларын үткәргәндә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге турында мәгълүмат бирү |
| 11. | Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының рәсми сайтында урнаштырылган эшмәкәрлек субъектларына карата тикшерүләр үткәрүнең еллык җыелма планы нигезендә юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә планлаштырылган тикшерүләр турында мәгълүмат бирү |
| 12. | «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенең микрозаймын алуга документлар кабул итү |
| 13. | Бизнес-инкубация һәм кластерлы үсеш үзәге биналарында ташламалы шартларда урнаштыру мәсьәләләре буенча консультация бирү |
| 14. | Социаль өлкә инновацияләр үзәгенең ярдәм чаралары, хезмәтләре һәм үткәрелә торган чаралары турында мәгълүмат бирү |
| 15. | Экспортка ярдәм итү үзәгенең ярдәм чаралары, хезмәтләре һәм уздырыла торган чаралары турында мәгълүмат бирү |
| 16. | Эшмәкәрлеккә ярдәм итү үзәгенең ярдәм чаралары, хезмәтләре һәм чаралары турында мәгълүмат бирү |
| 17. | Кластерга керү мәсьәләсе буенча консультация бирү |
| 18. | «Эшмәмәкр йорты»нда чаралар оештыру мәсьәләләре буенча консультация бирү |
| 19. | Эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруны планлаштыручы физик затлар өчен үз эшен башлап җибәрү мәсьәләләре буенча консультация бирү»; |

«Күпфункцияле үзәкләр яки алар җәлеп иткән чит оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Күпфункцияле үзәкләр яки алар җәлеп иткән чит оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр | |
|---|---|
| 1. | Күчермә, күбәйтү хезмәтләре күрсәтү |
| 2. | Юридик зат өчен электрон цифрлы имза эшләүгә гаризалар кабул итү |
| 3. | «Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гражданнарны теркәү |
| 4. | Банкта исәп-хисап счеты ачу өчен юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр гаризаларын кабул итү |
| 5. | «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимы буенча консультацияләр бирү |
| 6. | «Эшмәкәр йорты»нда коворкингта урын бирү |
| 7. | Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү өчен гаризалар кабул итү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин